**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423737, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75, а йорты
e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru

**СОВЕТ АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423737, село Атясево, ул. Центральная, д. 75, а
e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

21 ноябрь 2023 ел №15

«Актаныш муниципаль районының "Әтәс авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Актаныш муниципаль районының "Әтәс авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» гы нигезләмэгэ узгэрешлэр керту турында

Прокурорның 2023 елның 30 июнендәге 02-08-02-2023 номерлы протестын үтәү йөзеннән "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 01.04.2022 N 90-ФЗ, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Әтәс авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Актаныш муниципаль районының «Әтәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Актаныш муниципаль районының «Әтәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең 2015 елның 10 гыйнварындагы N 3 номерлы карары белән расланган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (2015 елның 22 ноябрендэгедәге №10, 05 июль 2018 елның №15, 08 февраль 2021 ел №11 нче номерлы карарларда кертелгән үзгәрешләр белән) бирү, белешмәләр тапшыру хакында»гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16 нчы пунктның икенче абзацында «яисә тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «үз чыгымнары турында белешмәләр, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, дорес булмаган белешмәләр бирү, яисә белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга,

«яисэ хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмэлэр тапшырмау яисә дорес булмаган белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләрен «яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, дорес булмаган белә торып та тулы булмаган белешмәләр тапшыру,» сүзләренә алыштырырга.

1.2 Нигезләмәнең 6 пунктындагы «в» пунктчасында һәм 13 пунктындагы «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районы "Әтәс авыл җирлеге" рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Әтәс авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Насирова